ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында” Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында” 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның тугызынчы абзацында “2 өлешенең 62, 63 пунктлары” сүзләрен “2 пунктының 62, 63 пунктчалары” сүзләренә, “белгечләр әзерләү, аларны яңадан укыту һәм аларның квалификациясен күтәрү” сүзләрен “белгечләргә һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру” сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяда “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында” 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы” сүзләрен “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОТДЕЛ ОБЩИЙ

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 16-ТРЗ